## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлегенең Тегермәнлек торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**15 ноябрь 2023 ел** **№2**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына ярашлы рәвештә, 2023 нче елның 15 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде) Сез 2024 нче елда, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлегенең Тегермәнлек торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы, 1 төркем инвалидлардан, Әфганстанда (ДРА) хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан, локаль конфликтларда (Чечня) хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан тыш, алар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә һәм үзара салым түләүдән гражданнар-контрактчыларны, СВО зонасында хезмәт итүче гражданнар һәм өлешчә мобилизация буенча чакырылган гражданнарны, шулай ук балигъ булган балаларын, хатынын, алар булмаганда, әлеге гражданнарның ата-аналарын түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

**I. <u>Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:</u>**

1) Янгын сүндерү машинасын карап тоту - АҖ буенча
2) Янгын сүндерү өчен сыйдырышлы савыт сатып алу - АҖ буенча

**II. <u>Урам яктырту җайланмасы, ремонт:</u>**

1) Урам яктыртуын тәэмин итү, ремонтлау - АҖ буенча
2) Лампалар сатып алу - 15 данә - АҖ буенча

**III. Су белән тәэмин итү һәм су җибәрү системаларын, су башнясын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын ремонтлау, су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, ташуын һәм халыкка су бирүне тәэмин итү:**

1) Су башнясын ремонтлау, һәлакәт нәтиҗәләрен бетерү

**IV. <u>Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлеге:</u>**

1) Юлларны карап тоту - җәйге чорда - АҖ буенча
2) Юлларны карап тоту - кышкы чорда - АҖ буенча
3) Х.Такташ урамы юлын төзекләндерү һәм ремонт өчен кирәкле материаллар сатып алу
4) Трактор өчен кар эттергеч җайланмасы сатып алу - АҖ буенча
5) Тактор өчен печән чапкыч машина сатып алу - АҖ буенча
6) Юл кырындагы үләнне чабу - АҖ буенча
7) Трактор өчен ягулык – майлау материаллары сатып алу - АҖ буенча

**V. <u>Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:</u>**

1) Массакүләм чаралар урынын төзекләндерү, материаллар сатып алу - АҖ буенча

**VI. <u>Ритуаль хезмәтләр һәм күмү урыннарын карап тотуны оештыру</u>**

1) Зиратта үлән чабу

2) Печән чапкыч машина өчен бензин сатып алу.
3) Кул печән чапкычы сатып алу – 2 (ике) данә – АҖ буенча
4) Каты коммуналь калдыкларны чыгарту
5) Койма-киртәләрне ремонтлау.»

**«РИЗА»** **«КАРШЫ»**

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының 64 катнашучысы, 38 кеше тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны кертелгән, бу 59% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенының 38 катнашучысы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены **карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Түбән Табын авыл җирлеге Тегермәнлек торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2024 нче елда, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлегенең Тегермәнлек торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы, 1 төркем инвалидлардан, Әфганстанда (ДРА) хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан, локаль конфликтларда (Чечня) хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан тыш, алар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә һәм үзара салым түләүдән гражданнар-контрактчыларны, СВО зонасында хезмәт итүче гражданнар һәм өлешчә мобилизация буенча чакырылган гражданнарны, шулай ук балигъ булган балаларын, хатынын, алар булмаганда, әлеге гражданнарның ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итәргә.

3.Түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

**I. <u>Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:</u>**
1) Янгын сүндерү машинасын карап тоту - АҖ буенча
2) Янгын сүндерү өчен сыйдырышлы савыт сатып алу - АҖ буенча

**II. <u>Урам яктырту җайланмасы, ремонт:</u>**
1) Урам яктыртуын тәэмин итү, ремонтлау - АҖ буенча
2) Лампалар сатып алу - 15 данә - АҖ буенча

**III. Су белән тәэмин итү һәм су җибәрү системаларын, су башнясын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын ремонтлау, су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, ташуын һәм халыкка су бирүне тәэмин итү:**
1)Су башнясын ремонтлау, һәлакәт нәтиҗәләрен бетерү

**IV. <u>Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлеге:</u>**
1) Юлларны карап тоту - җәйге чорда - АҖ буенча
2) Юлларны карап тоту - кышкы чорда - АҖ буенча

3) Х.Такташ урамы юлын төзекләндерү һәм ремонт өчен кирәкле материаллар сатып алу
4) Трактор өчен кар этттергеч җайланмасы сатып алу - АҖ буенча
5) Тактор өчен печән чапкыч машина сатып алу - АҖ буенча
6) Юл кырындагы үләнне чабу - АҖ буенча
7) Трактор өчен ягулык – майлау материаллары сатып алу - АҖ буенча

V. **Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**
1) Массакүләм чаралар урынын төзекләндерү, материаллар сатып алу - АҖ буенча

VI. **Ритуаль хезмәтләр һәм күмү урыннарын карап тотуны оештыру**
1) Зиратта үлән чабу
2) Печән чапкыч машина өчен бензин сатып алу.
3) Кул печән чапкычы сатып алу – 2 (ике) данә – АҖ буенча
4) Каты коммуналь калдыкларны чыгарту
5) Койма-киртәләрне ремонтлау.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Түбән табын авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Түбән табын авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә

**Түбән Табын авыл җирлеге башлыгы** **Р.Ш. Кыяметдинов**